**(Бишенче чакырылыш)**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Микулино авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Микулино авылы № 4 01 апрель 2026 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясе Президентының кайбер актларын үзгәртү һәм аларның үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә

Микулино авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Микулино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшыру Тәртибе турында» 2017 елның 31.08 61 номерлы;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының Микулино 2017 елның 31.08 61 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының « Микулино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшыру Тәртибе турында» 2018 елның 30.03 90 номерлы;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының 2017 елның 31.08 61 номерлы карары белән расланган (30.03.2018 №90 карар редакциясендә) Татарстан Республикасы Азнакай

муниципаль районының « Микулино авыл жирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына тапшыру Тәртибе турында» 2022 елның 13.04 49 номерлы.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис И.А.Такиулин